СОВЕТ
АКБУРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Октябрьская, д. 44,
с. Акбуре, 423197

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКБҮРЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Октябрь урамы,44 нче йорт
Акбүре авылы, 423197

тел.: (8-84348) 3-62-40, факс: (8-84348)3-62-40, Akbur.Nsm@tatar.ru

КАРАР КАРАР

2020 елның « 2 » ноябреннән № 1

“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлегенең Сөлчә Баш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены уткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Акбуре авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлегенең Сөлчә Баш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 10.00 сәгать , 2020 елның 28 ноябрендә Сөлчә Баш авыл клубында (Урман ур., 8 йорт) билгеләргә.

2. Гражданнар җыенының этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлегенең Сөлчә Баш территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, 1 төркем инвалидлардан кала һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Сөлчә Баш территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- су башнясын, су алу скважинасын ремонтлау һәм төзеклэндерү (материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлегенең Акбуре авылының мәгълүмат стендларында урнаштырырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акбуре авыл җирлеге башлыгы Җ.М.Җәләлетдинов